# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Айбаш авыл җирлеге Айбаш торак пунктында 09.11.2019
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

5 декабрь 2019 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 9 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта уздырылган “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Айбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

а) урам утларын ремонтлау

б) һәйкәлләрне һәм һәйкәл әйләнәсен ремонтлау

в) авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау (вак таш, асфальт валчык, кышкы юлларны карап тоту).

г) балалар мәйданчыгын төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 232 (ике йөз утыз ике) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 140 кеше, бу 60,3 % ны тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 130 (бер йөз утыз) катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 10 (ун) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Айбаш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2020 елда үзара салым акчасын яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Айбаш авыл җирлеге Айбаш торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган һәр кешедән 300 (өч йөз) сум күләмендә кертергә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлтергә:

а) урам утларын ремонтлау

б) һәйкәлләрне һәм һәйкәл әйләнәсен ремонтлау

в) авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау (вак таш, асфальт валчык, кышкы юлларны карап тоту).

г) балалар мәйданчыгын төзекләндерү

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Айбаш авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Сафиуллин